**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«28» март 2024г.** **№ 43**

Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыкка каршы сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында

«Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законның 5.2 статьясы нигезендә, «Теләче» Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең 2024 елның 07 мартындагы 11 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан мәгариф оешмалары (алга таба - мәгариф оешмасы) объектларының (территорияләренең) террорчылыкка каршы сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү бәясенең нормативларын расларга, хосусый сак оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда:

- беренче куркынычлык категориясендәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен - бер саклау постына сәгатенә 180 сум күләмендә;
- икенче куркынычлык категориясендәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен - бер саклау постына сәгатенә 180 сум күләмендә;
- өченче куркынычлык категориясендәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен - бер саклау постына сәгатенә 180 сум күләмендә.

2. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин